| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ<br>КОМИТЕТ<br>ЧЕРЕМШАНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

18.12.2025 **Чирмешән авылы** **№ 406**

**2026 елда Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы халкына күрсәтелә торган торак хезмәтләр өчен түләү күләмен раслау турында**

Россия Федерациясе Торак кодексының 156,158 статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне карап тоту кагыйдәләрен һәм күпфатирлы йортта тиешле сыйфатта булмаган гомуми мөлкәт белән идарә итү, карап тоту һәм ремонтлау буенча хезмәтләр күрсәткән һәм эшләр башкарган очракта һәм (яисә) билгеләнгән дәвамлылыктан артыграк тәнәфесләр белән торак урынны карап тоту һәм ремонтлау өчен түләү күләмен үзгәртү кагыйдәләрен раслау турында» 2006 елның 13 августындагы 491 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. 2026 елның 1 гыйнварыннан 2026 елның 31 декабренә кадәр расларга һәм гамәлгә кертергә:

- күпфатирлы торак йортлар белән идарә итү ысулын сайламаган торак урыннар милекчеләре өчен, муниципаль торак фондының торак урыннарын яллаучылар өчен торак урынны карап тоту һәм ремонтлау өчен түләү күләме, күпфатирлы торак йортлар белән идарә итү ысулын сайлаган торак урыннар милекчеләре өчен һәм күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар һәм (яисә) гомуми җыелышта торак урыннарны карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләре өчен түләү күләме (1 нче кушымта);
- муниципаль торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннарны яллаучылар өчен торак урыннан файдаланган өчен түләү күләме (наемга түләү) (2 нче кушымта);

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан

Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына М.Г. Вильдановка йөкләргә.

Башкарма комитет
җитәкчесе И.М. Җамалетдинов

Чирмешән муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесенең
«18»12.2025 ел, № 406 карарына
1 нче кушымта

Күпфатирлы торак йортлар белән идарә итү ысулын сайламаган торак урыннар милекчеләре өчен, муниципаль торак фондының торак урыннарын яллаучылар өчен торак урынны карап тоту һәм ремонтлау өчен түләү күләме, күпфатирлы торак йортлар белән идарә итү ысулын сайлаган торак урыннар милекчеләре өчен һәм күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар һәм (яисә) гомуми җыелышта торак урыннарны карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләре өчен түләү күләме

| № п/п | Түләү атамасы | Хезмәтне үлчәү берәмлеге | Хезмәт күрсәтүне үлчәү берәмлеге өчен тариф (сумнарда) |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1 | Торак фонды белән идарә итү | аена торак бинаның гомуми мәйданы кв.м. | 2,28 |
| 2 | Торак биналарны агымдагы ремонтлау | аена торак бинаның гомуми мәйданы кв.м. | 1,55 |
| 3 | Йорт эчендәге суүткәргеч-канализация челтәрләренә техник хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау | аена торак бинаның гомуми мәйданы кв.м. | 1,84 |
| 4 | Йорт эчендәге электр белән тәэмин итү челтәрләрен агымдагы ремонтлау һәм карап тоту | аена торак бинаның гомуми мәйданы кв.м. | 1,72 |
| 5 | Вентиляция каналларына техник хезмәт күрсәтү | аена торак бинаның гомуми мәйданы кв.м. | 0,40 |
| 6 | Дератизация (дезинсекция) | аена торак бинаның гомуми мәйданы кв.м. | 0,20 |
| 7 | Газүткәргечнең йорт эчендәге челтәрләренә техник хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау | аена торак бинаның гомуми мәйданы кв.м. | 0,28 |
| 8 | Йорт яны территориясен җыештыру | аена торак бинаның гомуми мәйданы кв.м. | 1,55 |
| 9 | Газ челтәрләренә техник диагностика ясау (түләү диагностика ясау срогы башланганчы 12 ай эчендә исәпләнә) | аена торак бинаның гомуми мәйданы кв.м. | 0,25* |

* газүткәргеч файдалануга тапшырылуга 30 ел узган күпфатирлы йортлар өчен.

Чирмешән муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесенең
«18»12.2025 ел, № 406 карарына
2 нче кушымта

Муниципаль торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннарны яллаучылар өчен торак урыннан файдаланган өчен түләү күләме (наемга база ставкасы)

| Түләү атамасы | Хезмәтне үлчәү берәмлеге | Хезмәт күрсәтүне үлчәү берәмлеге өчен база ставкасы (сумнарда) |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| Торак урынны наемга алган өчен түләүнең база күләме | аена торак бинаның гомуми мәйданы кв.м. | 8,47 |